# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлегенең Дусай Кичү торак пунктында гражданнарга үзара салым кертү турында**

**28 ноябрь 2024 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлегенең Дусай Кичү торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

Карар кабул ителде:

1. Минзәлә муниципаль районының Яңа Мәлкән авыл җирлегенең Дусай-Кичү торак пункты территориясендә 1 һәм 2 төркем инвалидларыннан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы, сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан , махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә .

2. Кергән акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту - Дусай-Кичү торак пунктындагы Җәлил урамындагы авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, эш өчен килешү буенча түләү).

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Яңа Мәлкән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. http://menzelinsk.tatarstan.ru һәм Татарстан

Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: __________ Нәҗметдинов З.И.

Яңа Мәлкән авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе __________ Нәҗметдинов З.И.